ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
ГАБУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ

Айдар
ФӘЙЗРАХМАНОВ

БОРЧЫЛМА

җырлар һәм романслар

КАЗАН
2018

Фәйзрахманов А. Ф.
Борчылма: җырлар һәм романслар

Кереш мәкалә авторы, җыентыкны төзүче –
Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты,
профессор,
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм
Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт
ансамбленең сәнгать җитәкчесе А. Ф. ФӘЙЗРАХМАНОВ

РЕДКОЛЛЕГИЯ:
Рецензентлар Р. Г. Фәйзуллин, И. Ф. Камалов
Мөхәррире Г. Ф. Шәрапова
Музыкаль мөхәррире И. Ф. Камалов


Әсәрләрне фортепианога кушылып башкару өчен
эшкәрттеләр:
Ильяс Камал (1-7, 9-10, 12-20, 22-36)
Динә Хәкимова (8, 11, 21)

Фәйзрахманов А.Ф.
«Борчылма»: җырлар һәм романслар – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2018. – 122 б.

ISBN 978-5-905160-12-7

© А. Ф. Фәйзрахманов. 2018 ел.

ЕГЕТЛЕК



Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле. Күрәсез, ансамбль атамасында безнең өчен бик тә кадерле сүзләр: Татарстан, Республика, Дәүләт... Ансамбльнең эшчәнлеге дә Республика кимәлендә югары һәм дәрәҗәле булырга тиешлеген аңлата бу сүзләр. Шөкер, ике дистәгә якын еллар эчендә коллектив бу таләпне үтәп, халык ышанычын аклый алды. Беренче чиратта, ансамбльнең җитәкчесе, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзразмановның җиңүе бу.

Глобальләшү шаукымы чорында халыкларга, бигрәк тә, аз санлыларга, милләт буларак, үзенең рухи йөзен саклап калу җиңел түгел. Хәтта бик тырышканда да, килеп үк чыкмаска мөмкин. Милли-этник үзгәлекне саклауда, әлбәттә, халык иҗатының чын үрнәкләрен пропагандалау – үтемле алым. Әмма шарты бар: фәкать чорлар сынавын узган чын әсәрләр, чын җәүһәр җыр-көйләр аша гына! Халык иҗаты дип саналган гүзәл әсәрләрне дә кайчандыр аерым конкрет, хәзергечә әйтсәк, югары дәрәҗәдәге профессиональлеккә ия талантлар тудырган бит! Айдар Фәйзрахманов – җырчы, музыкант, оештыручы буларак – чын профессионал. Әгәр тормышыбызның һәр өлкәсендә үз вазифаларын профессионаллар башкарса, бу дөнья шактый камил булыр иде!

Соңгы елларда Айдар Фәйзрахманов зур активлык белән җырлар иҗат итә башлады. Олыгайган көндә яшьләргә хас үҗәтлек белән нигә тотынды икән бу эшкә дип уйлаучылар да бардыр... Хәер, нигә гаҗәпләнергә? Үзе – җырчы (әле ниндие генә!), үзе – музыкант (халык көйләрен үз йөрәге аша кичергән зат, өстәвенә, ансамбль үз кулында)... Эстрада нинди хәлгә (әрсез үзешчәннәр баскан заман) калганын күрә торып, җырларыбызның, көй-моңнарыбызның киләчәгенә ничек битараф кала алсын ул! Бу өлкәдә хәл кадәри үзеннән өлеш кертергә теләве дип аңлыйм мин аның җырлар язуын. Хезмәтенең асылын Вакыт бәяләр.

Айдар минем дә берничә шигыремә көй язган булып чыкты. Дөресен әйткәндә, махсус җыр текстлары язу остасы түгел мин. Шулай да, маэстро эзләнгән, нәрсәдер тапкан. Гомумән, татар поэзиясен яхшы белә Айдар, нечкә зәвыгы белән нәрсәнең нәрсә икәнен яхшы тоя. Игътибары өчен рәхмәт аңа. Моннан ике ел элек, 2016 елда Айдар Фәйзрахманов «Олы юл» дип исемләнгән, җырлар һәм романслар тупланган китап чыгарган иде. Китапка кереш сүзне шагыйрә Илсөяр Иксанова язган. Анда мондый сүзләр бар: «Һич кенә дә җыр булыр дип кузалламаган шигырьләремнең үз көйләрен табып бирде Айдар абый. Һәм иң гаҗәпләндергәне, һәм сөендергәне дә – ул көйләр шигырь тугандагы күңел халәтемә аваздаш». Миңа да шундый кичерешләр насыйп булса иде!

Айдар Фәйзрахманов – бар булмышы белән егет кеше. Бу сыйфат борын-борыннан зур мәртәбә саналган, хәзер – бигрәк тә! Уңышлар юлдаш булсын Сиңа, Зур Шәхес, газиз милләттәшем!


Равил ФӘЙЗУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре,
Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре,
Г. Тукай һәм М. Җәлил дәүләт премияләре лауреаты.







АЙДАР АБЫЙ МОҢНАРЫ



Айдар абый Фәзрахмановның иҗаты бүгенге татар җыр сәнгатендә аерым урын алып тора. Аның җырларында татар халык иҗатыннан илһам алган моң, классик романслар жанры алымнары, 20нче гасыр эстрада җырлары һәм Айдар абыйның үзенә генә хас булган кабатланмас аһәңнәр бергә кушылып, башка бер генә авторга да охшамаган аерым стиль булып формалашкан. Шунлыктан, аның җырларын күп кенә профессиональ җырчыларның яратып башкаруы табигый. Айдар абый җыр сүзләренә бик игътибарлы. Бары тик профессиональ, тирән мәгънәле шигъри әсәрләрне генә күңеленә сеңдерә ул. Шул вакытта гына көй белән сүзләр тәңгәл гармониядә булган музыкаль әсәр туа ала.

Ритмик структураларга килгәндә – Айдар Фәйзрахмановның җырларында үзгәрүчән такт размерлары – бик еш күренеш. Моның сәбәбе, әлбәттә, көйнең сүзләр белән өзелмәслек бәйләнештә булуыннан килә. Нәтиҗәдә «һава сулагандай», җанлы һәм табигый аһәңнәргә бай җырлар килеп чыга.

Айдар абыйның көйләре мелодизм ягыннан бик үзенчәлекле: бер яктан караганда ул – халкыбызның яраткан композиторлары Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова стилистикасын дәвам итүче, икенче яктан – фольклорга бүгенге көн күзлегеннән карап, аннан илһам алып, үзенә генә хас булган өр-яңа интонацияләр белән баетылган җырлар тудыручы.

Айдар Фәйзрахманов җырларын һәркем башкара алмый, аларның күбесе зур профессиональ әзерлек таләп итә, әмма шул ук вакытта, алар музыка уку йортларында белем алучы студентларга – булачак профессиональ җырчыларга үсеш өчен бик файдалы әсбап буларак та әһәмиятле һәм, әлбәттә, алар профессиональ җырчыларның репертуарларында урын алырга бик лаек.

Әлеге басманың китап киштәләрендә кулланусыз ятмаячагына һәм аны кулына алган һәр музыка сөюченең күңелендә урын алырына ышанам.

Ильяс КАМАЛ,
Татарстан һәм Россия Федерациясенең
композиторлар берлеге әгъзасы,
композитор,
Г. Тукай исемендәге
Татар Дәүләт филармониясе солисты.

ИЖАДИ ЮЛЛАМА



Мөхтәрәм яшь җырчы дустым! Сиңа үземнең җырларым һәм романсларым тупланган тагын бер җыентыгымны тәкъдим итәм. Монысы – өченчесе. Әлегәчә дөнья күргәннәре «Яшәү барыбер кызык» һәм «Олы юл» җыентыклары иде. Һәрберсенә тупланган әсәрләр җыентыкның асылына, исеменә тәңгәл килеп торалар. Яңа җыентыкның исеме «Борчылма» дип атала. Нигә «Борчылма»? Югыйсә борчылырга урын бар кебек: үзгәреш кичерәбез, аның җилләре милли сәнгатебезгә дә килеп кагылалар, әмма... Җиһанда мәңгелек төшенчәләр бар: ул – туган ил, туган туфрак, туган тел, туган моңнар, милләт, әти-әни, бала һәм башкалар. Аларны син дә, мин дә, вакыт та үзгәртә алмый. Алар бар һәм булачак! Мин моңа ышанып яшим!

Җырны көйләп, җырны тыңлап, аның асылында кайсы милләт аһәңнәре, кичерешләре ятканны бик тиз аңлап була, һәм бу, мөгаен, иң кыйммәтлесе, сәнгатебезнең асылыдыр. Татар җыры да шулай булырга тиеш. Аның асылында – татар моңы, көй агышы, бормалары (мелизматика) ята. Әлбәттә, җыентыкка тупланган әсәрләрне башкару югары профессиональ әзерлек таләп итә. Мин аларны нәкъ шулай күзаллап яздым да. Алар барлык музыкаль кануннарга туры килә. Көй һәм шигъри юлларның бер-берсенә тәңгәл килүе дә, тесситура, диапазон, көй агышы, ритмик сурәт – барысы да моңа дәлилләр.

Әйе, «Җырның ертыгы юк», ди безнең халык мәкале. Әмма башка мәкальләр дә бар. «Карга каңгылдап каз булмас», «Тел әйтә алмаганны – җыр әйтер», «Сандугач җырын җырлыйм дип, үз җырыңны онытма». Монысы инде нәкъ безгә карата әйтелгән. Тагын бер мәкаль: «Илнең җыры бар, күңелнең моңы бар». Без бит үз илебезнең моңлы балалары.

Мин сиңа, мөхтәрәм җырчы дустым, юлдашым, берникадәр борчылып, әмма да ышанып, күңелемнең моңнарын җиткерәм. Уңышлар телим!

Россиянең атказанган,
Татарстанның халык артисты,
профессор,
Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Айдар
ФӘЙЗРАХМАНОВ

БОРЧЫЛМА

җырлар һәм романслар

Абзыеңның кәләпүше

И. Юзеев А. Фәйзрахманов




17
ган ке - ше, бул - ган ке - ше – баш -
21
та бул - са кә - лә - пү - ше!
25
Зәң - гәр күк - кә дә - шеп то - ра, баш ю - га - ры – го - рур тү - ше.
29
И - ман ну - рын чә - чеп то - ра аб - зы - ең - ның кә - лә - пү -



2. Булмаса да өч – дүрт теше,
Тешле диеп кала кеше.
Кызларны да караттыра
Абзыеңның кәләпүше!

Кушымта:

Такыр башны каплап тора,
Бер кияү юк минем ише!
Күз тиюдән саклап тора
Абзыеңның кәләпүше!

Кода:

Зәңгәр күккә дәшеп тора,
Баш югары – горур түше.
Иман нурын чәчеп тора
Абзыеңның кәләпүше!

Авылыма кайту

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов




11
а - выл ба - шын - да - гы нә - ни и - неш
13
кар көр - те - нә күм(е) - леп кал - ган - дыр.
15
А - выл ба - шын - да - гы нә - ни и - неш
3
17
Кабатлау өчен
Тәмамлау өчен
кар көр - те - нә күм(е) - леп кал - ган - дыр. //юл бе -



2. Ак бүреген кырын салды микән
Басуларда эскерт өсләре?
Таралгандыр таңгы урамнарга
Яңа пешкән икмәк исләре.

3. Әткәемнән откан «Авыл көе»н
Сагынып җырлармын дип кем белгән...
Кайтып киләм әле, кыяр-кыймас,
Күптән чыгып киткән юл белән.

Ак поэма


Р.Әхмәтҗанов А.Фәйзрахманов

Andante con moto ♩.=60




15
гын! Ан - нан кер(е) - шә ай -
18
ның кө - меш йом - га - гы - на, жеп - ләр - нең ул сай -
22
лый иң а - гын... Шу -
25
лай бәй-ли ә - ни ай - лар, ел - лар... Сү -


29
тә - сү-тә го - ме - ре йом - га - гын!.. А -
33
на, түз! Са - гын,
36
көт, ак и - нәң - дә, ә - ни, ни - чә
39
күз? ...Те - зә



2. Кушып бәйли
Ак карларның яктылыгын,
Хыялларның көтелгәнен!..
Карый-карый
Күкләр тәрәшендә
Ап-ак йондай
Карлар тетелгәнен...

Кушымта:
Шулай бәйли әни
Айлар, еллар...
Сүтә-сүтә
Гомере йомгагын!..
Ана, түз!
Сагын, көт,
Ак инәңдә, әни, ничә күз?
...Тезә ул...
Ана – түзә ул!

Алып калыр өмет

М. Әгъләмов

А. Фәйзрахманов

Tempo di valse




13
Piu mosso
лә - рем - нән. Сы - нар и - дем ко - ры ку - ра ке - бек, я -
16
нып сү - нәр и - дем чы - ра ке - бек... "Яр -
18
га жит - ми... ба - там, бе - тәм" ди - гәч, а -
20
3
лып чы - гар ми - не, а - лып чы -



2. Актарылып, шашып килә болыт,
Ул беләдер, әлбәт, бушанасын.
Күптән чыгар идең исләремнән,
Минем һаман килә ышанасым.

Кушымта:

Ышанмасам, терәк бетәр кебек,
Гомер шулай үтеп китәр кебек.
«Ярга җитми... батам,
Бетәм» дигәч,
Алып чыгар мине,
Алып чыгар өмет!

Әгәр миңа ышанмасаң...

Р. Фәйзуллин А. Фәйзрахманов




21
-дән со - рап ка - ра! А - лар да, ми-нем ши - кел - ле,"Шу - ны да
26
бел - ми - сең - ме?"дип, чә- чең - нән та - рап то - рыр. Ә - гәр ми - ңа ы -
31
Кабатлау өчен
шан - ма - саң.
35



2. Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул миңа тугрымы?» дип,
Күкләрдән сорап кара!
Болытлар, минем шикелле,
«Шуңа шикләнәсеңме?» дип,
Мөлдерәп карап торыр.
Әгәр миңа ышанмасаң...

3. Әгәр миңа ышанмасаң,
Шул ук сорауны биреп,
Үзеңнән сорап кара!
...Күңелең тулы яшь булып та,
Көлеп, елмаеп кара!
Үзең мин булып кара!
Әгәр миңа ышанмасаң...

Бар күңелләрдән җылы,
Йомшак синең кабрең ташы.
Г. Тукай

Әни ишетмәгән җыр

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




12
2.
та та - бы - лыр.
//кәң - нең йө - рә - ге ка - бы - ныр.
15
Яшь чак - та, сау чак - та
Хәс - рәт - кә та - ры - саң,
16
да - ны - ңа, ма - лы - ңа, җа - ны - ңа дус - лар да, яр - лар да
до - га - да, күк - ләр - гә и - ле - реп, тик га - зиз ән - кә - ең



2. Яшь чаклар, сау чаклар,
Болыттай, мәңгегә кайтмаска,
Җилләргә сарылып агылыр.
Ахыргы көндә дә
Чәчәкләр күзендә күрерсең –
Әнкәең карашы чагылыр.

Кушымта:

Яшь чакта, сау чакта
Даныңа, малыңа, җаныңа
Дуслар да, ярлар да сарылыр.
Хәсрәткә тарысаң,
Догада, күкләргә илереп,
Тик газиз әнкәең сагыныр.

Әни

К. Сибгатуллин А.Фәйзрахманов





2. Куанып ятам әнинең
Исән-сау көннәренә.
...Аяк очларына басып
Су сибә гөлләренә.
Кушымта:
Тыңлап ятам: мин әнинең
Бар гомерен ишетәм.
...Аяк очларына басып
Чыга әни ишектән.

3. Атасы, дип, балалар, дип,
Үзе дә сизми бугай,
Аяк очларында йөрде
Гомере буе шулай.
Кушымта.

Әнкәем – сердәшемә

С. Әхмәтҗанова

А. Фәйзрахманов





2. Чәчләремнән сыйпа әле, әни,
Тойыйм кулларыңның җылысын.
Изге йөрәгеңә сыйдыргансың
Мәхәббәтнең иң-иң олысын.

3. Өзми – куймый бәхетем сайраганда,
Син һәрвакыт әзер тыңларга;
Җанымдагы телсез сагышларны
Ярый син бар сүзсез аңларга.

Без, бәләкәй чакларда
сикереп мендек атларга!
Халык җыры

Без, бәләкәй чакларда

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




16
оч - ра-шу - га чак(ы) - ра и - дек ау - ла - гы - рак чат - лар- га...
20
Без, бә-лә - кәй чак-лар-да, мен-мә-сәк тә ат - лар-га.
24
Әй, ку-ан-дык "сө - ю" сү - зе бул-ган җы - лы хат - лар - га!
29
Кабатлау өчен
Без, бә - лә - кәй чак - лар - да!



2. Без бәхетле чакларда,
Булдык җылы кочакларда.
Көнләшүдән җан дуслар да
Әйләнделәр ятларга.
Без, бәләкәй чакларда,
Менмәсәк тә атларга,
Бәлки, олайган чакларда
Килмәс җылы хатлар да...
Без, бәләкәй чакларда!


3. Без, бәләкәй чакларда,
Менмәсәк тә атларга,
Ә шулай да ант иттек без
Сынатмаска ятларга.
Без, бәләкәй чакларда
Сикереп мендек атларга.
Яшеннәргә тиң яшьлекнең
Шанлы исемен акларга.
Без, бәләкәй чакларда!

Борчылма!

Р. Фәйзуллин А. Фәйзрахманов




14
бар - - - бор - чыл - ма!
17
А - кы - лың жу - яр - лык шат - лык - лар кил - гән - дә, жир хи - сен ю - гал - тып,
20
күк - кә(а) шам ди - гән - дә, ы - ша - ныр ке - шең бар - - -
23
1.
2.
бор - чыл - ма!
бор - чыл -



2. Кайгылар ишәйгән
Борчулы көннәрдә,
Күңелең тулышып
Сыгылып төшкәндә,
Тураеп торырга
Таяныр кешең бар –
Борчылма!

Кушымта:

Акылың җуярлык
Шатлыклар килгәндә,
Җир хисен югалтып,
Күккә ашам дигәндә,
Ышаныр кешең бар –
Борчылма!

Елмай әле бер генә

Р. Мингалим А. Фәйзрахманов




16
Ма - ту - рым, гөл ге - нәм, ел - май ә - ле бер ге - нә!
20
1.
Мә кулъ - яу - лык, сөрт я - шең - не, сөй - лә се - рең үзе - мә.
24
2.
сөй - лә се - рең үзе - мә. Мә кулъ - яу - лык,
27
сөрт я - шең - не, сөй - лә се - рең үзе - мә.

1. Ниләр булды үзеңә,
Ике кара күзеңә?
Мә кулъяулык, сөрт яшеңне,
Сөйлә серең үземә.
Кушымта:
Матурым, гөл генәм,
Елмай әле бер генә!
Мә кулъяулык, сөрт яшеңне,
Сөйлә серең үземә.

2. Йөзең түгәрәк кенә,
Үзең күбәләк кенә.
Керик әле бакчаларга,
Йөрик бергәләп кенә.
Кушымта:
Матурым, гөл генәм,
Елмай әле бер генә!
Мә кулъяулык, сөрт яшеңне,
Сөйлә серең үземә.

3. Гөл биреп юатыймммы,
Биримме сабырлыгым?
Буйларыңа туры килми
Уйларың авырлыгы...
Кушымта:
Матурым, гөл генәм,
Елмай әле бер генә!
Мә кулъяулык, сөрт яшеңне,
Сөйлә серең үземә.

Җәйләр соңы

И. Иксанова

А. Фәйзрахманов





* 2нче куплет өчен вариант.

1. Җәйләр соңы, җәйнең соңы,
Иртәләрдә
Көзләр тыны,
Көзләр тыны.
Кушымта:
Гомеркәйләр узып бара,
Ап-ак хисләр сибелеп кала, –
Зая түгел узган гомер,
Сызма күңел!

2. Җәйләр соңы, җәйнең соңы,
Һаваларда
Кошлар моңы,
Кошлар моңы.
Кушымта:
Гомеркәйләр узып бара,
Кошлар юлы күкне яра.
Зая түгел үткән язлар,
Сау булыгыз,
Киек казлар!

3. Җәйләр соңы, җәйнең соңы,
Өзелердәй
Күңел кылы,
Күңел кылы!
Кушымта:
Гомеркәйләр узып бара,
Яфрак булып йөрәк яна.
Зая түгел узган гомер,
Сызма, күңел!

Имин генә булсын татар-йорт!

Җ. Сөләйман А. Фәйзрахманов




16
2.
бул-сын та-тар - йорт!
//и - мин ге - нә бул-сын та-тар- йорт!
19
piu f
Дөнь - я тү - гел, без үзе-без ат - лар, кам - чы - лар - дан ю - еш ка-еш- сырт,
piu f
23
1. poco p
без тү-зә - без, без тар-та-быз йөк- не, и - мин ге - нә бул-сын та-тар - йорт!
poco p
27
2. poco p
//без тү-зә - без, без тар-та-быз йөк - не, и - мин ге - нә бул-сын та-тар- йорт!
poco p



2. Кемдер әйтә: «Беттек!», кемдер елый,
Илен җуйган күпмеләп маңкорт,
Ир-егетләр атын-исемен җуймас –
Имин генә булсын татар-йорт!

Кушымта:

Дөнья түгел, без үзебез атлар,
Камчылардан юеш каеш-сырт,
Без түзәбез, без тартабыз йөкне,
Имин генә булсын татар-йорт!

Истәлек

Инструменталь әсәр

А. Фәйзрахманов




13
(8)
2
17
(8)
mf
mp
20
(8)
23
(8)


26
3
f
mf
30
4
33
1.
2.
Coda
35

Кичер, болыным!

Р. Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов





2. Кичер мине, болыным, кайткан саен
Гөлләреңне өзгән өчен дә...
Кичер, болыным!
Туган җирнең тоеп гүзәллеген,
Тугайларны гизгән өчен дә.

3. Кичер, мине, болыным, күпсенмә син
Чишмәләрдән эчкән суыңны...
Кичер, болыным!
Оныттыңмы яшел тауларыңда
Яланаяк чапкан улыңны?

4. Кичер, болыным, инде ераклардан
Яннарыңа сирәк кайтканга.
Кичер, болыным!
Куеныңда калган балачакның
Тавышы килә таңнар атканда.


Кичке кошлар

Р. Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




20
гыр - лы кич - ләр - дә, эң - гер төш - кән - дә, кү - мәк кош -
23
1.
лар төр - ке - ме - дәй, ә - нә шу - лай кай - та - лар ми - нем уй - ла -
27
Кабатлау өчен
- рым. Яң - //ми - нем уй - ла - рым.
31
Тәмамлау өчен
2. Шу - //ми - нем уй - ла - рым.



2. Шулай йөри
Минем җир өстендә,
Чит күк асларында
Җавап табалмаган сорауларым.
Кушымта:
Яңгырлы кичләрдә,
Эңгер төшкәндә,
Күмәк кошлар төркемедәй,
Әнә шулай
Кайталар минем уйларым...

3. Мең яшәп тә
Чигенә чыгалмаслык
Бу дөньяга
Күп очырдым бугай мин аларны!..
Кушымта.

Кошларымны көтәм

Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




9
Ту - ган як - ка кайт - кан кош - лар ю - лы
11
үтә, ах - ры, ми - нем кү - ңел - дән.
Кушымта (иркен)
13
Ни - гә шу-лай тан-сык кош - лар ө - не, кош сай - рау-дан са - гыш
16
ки - мер - ме? Кош - лар бу - лып, ах - ры,



2. Нигә шулай тыңлыйм искән җилне,
Әллә берәр хәбәр көтәмме?
Хәбәр түгел, көтәм кошларымның
Талга басып сайрар иртәне.

Кушымта:

Нигә шулай тансык кошлар өне,
Кош сайраудан сагыш кимерме?
Кошлар булып, ахры, җаным җырлый,
Искә алып үткән гомерне.

Көзге җыр

Р. Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




9
Ир-ат:
Бергә:
мас без - не: син бит күз - ал - мам ин - де лә, син бит
11
Хатын-кыз:
күз - ал - мам ин - де!.. Бә - гы - рем - не бер сүз өз - де:
13
Бергә:
"син - сез тү - зал - мам ин - де лә,
14
1.
син - сез тү - зал - мам ин - де!.."



2. Көзләр куенына сеңеп,
мин сине яраттым ла!..
Шул сүзләрем очты кебек
кыр казы канатында шул,
кыр казы канатында...

Кушымта:
Бәгыремне бер сүз өзде:
«Синсез түзалмам инде лә,
синсез түзалмам инде!..»

3. Булмас инде һичбер чаклар
безнең ул чаклар сыман!..
Кызыл-комач бу яфраклар
көзге учаклар сыман ла,
көзге учаклар сыман!..

Кушымта:
Бәгыремне бер сүз өзде:
«Синсез түзалмам инде лә,
синсез түзалмам инде!..»

4. Көз каршында берьялгызым
дөрлим учаклар сыман!..
Сезнең якларга очалмыйм...
инде ул яклар... томан...
дөрлим учаклар сыман.

Кушымта:
Бәгыремне бер сүз өзде:
«Синсез түзалмам инде лә,
синсез түзалмам инде!..»

Көзге мәхәббәтем

Р. Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




14
ныт - ма - ды. Хуш - ла - ша Җәй, ак яу - лык - лар бол - гап, аг(ы)-
18
ла бо - лыт - ла - ры... Си - не уй - лап мин
21
дә чир - тәм саз - ның көз - ге кыл - ла - ры - на. А -
24
вырт - тыр - ма, җан(ы) - ма ти - мә, көз - дәй чык -


26
1.
ма юл - ла - ры - ма! Си -
29
2.
Тәмамлау өчен
//ла - ры - ма! //ла - ры - ма! А -
mf
31
выртты - ма, җан(ы) - ма ти - мә, көз - дәй чык -
33
ма юл - ла - - ры - -



2. Сибелә яфрак эзләреңә, сары
Көзнең табышлары.
Кагыла җирнең, җан җиренә кагыла
Торна тавышлары!..

Кушымта:

Сине уйлап мин дә чиртәм сазның
Көзге кылларына.
Авырттырма, җаныма тимә, көздәй
Чыкма юлларыма!

3. Көзге мәхәббәтем сиңа түгел – аны
Көзге урман тыңлар.
Сиңа түгел, бәгърем!
Сулыгып – сулыгып, моңы
Ераста бер тынар...

Кушымта:

Сине уйлап мин дә чиртәм сазның
Көзге кылларына.
Авырттырма, җаныма тимә, көздәй
Чыкма юлларыма!

Кыз гомере

Г. Афзал

А. Фәйзрахманов




17
Чул - ман бу - е тал и - кән лә, алъ - яп-кы - чың ал и - кән.
21
А - сыл е - гет со - ра - ган - да, ал - ма бу - лып
24
там и - кән, Ал - ла-ры - на там и - кән.
27



2. Биегәндә чеметеп тотам
Яулыгымның читләрен.
Яшь чирәмдә очып йөри
Чәмчәле читекләрем.

Кушымта:

Чулман буе тал икән лә,
Алъяпкычың ал икән.
Асыл егет сораганда,
Алма булып там икән,
Алларына там икән.

3. Кыз гомере – гөл гомере,
И гөнаһсыз гөлләрем!
Ал чәчәктәй көннәремне
Гөлләремә тиңләдем.

Кушымта.

Мәхәббәт көянтәсе

Л. Шагыйрьҗан

А. Фәйзрахманов

Con moto ♩=120




19
са - ла-ват кү - пе - ре бу - лып мә - хәб - бәт кө - ян - тә - се.
23
Иң - нә-рен - дә кал - ды эл(е) - неп, кай - да соң чи -
26
1.
- ләк- лә - ре? Сө - ю - нең бер йо - тым су - дай
29
бар и - кән ки - рәк - лә - ре.



2. Барасы калды чишмәгә
Талир тәңкәләр тагып.
Чыңнарына чишмә үзе
Кушылыр хәйран калып.
Кушымта:
Иңнәрендә калды эленеп,
Кайда соң чиләкләре?
Сөюнең бер йотым судай
Бар икән кирәкләре.

3. Барасы калды чишмәгә
Пар чиләкләрне тагып.
Безнең мәхәббәт чишмәсе
Бетмәгән әле агып.
Кушымта.

4. Калды шул әле, калды шул
Яратам дип әйтәсе.
Иңнәремдә эленеп тора
Мәхәббәт көянтәсе.
Кушымта.

Мизгел

(Салкын кышның моңсу төннәрендә...)

Уты ялкын, суы салкын, –
Ай-һай якын үзтөбәк.
Төнлә кайтсам авылыма,
Утлар эзлим күз төбәп.

М. Әгъләмов

А. Фәйзрахманов




12
сә - фәр - гә... Мич ал-дын-да тез - лә - рем - не ко - чып
15
у-ты-рам мин, ут - ка күз са - лып... Мич тө - бен - дә ал - су -
18
ла - нып пеш - кән бө - тен ик - мәк төс - ле
20
1.
2.
кы - за - рып. //кы - за - рып.


22
6
mf
25
3
2.А - ның бе-ләң бер - гә сә - хәр а - шыйм,
mp
28
ул жи - бәр - сә у - чак тер - ге - зеп,
30
Ял - га - на күк и - де төн бе - ләң көн а - ра-сын-да бул - ган


33
бер ө - зек. ...Күз - лә - рем-дә ян - ган оч - кын-нар - ны
36
күреп сок-лан-са - гыз бе - ре - гез... Шул мич-ләр-дә дөр - ли -
39
дөр - ли ян - ган ут - лар оч - кы - ны дип
41
1.
2.
бе - ле - гез. бе - ле - гез.



1. Салкын кышның моңсу төннәрендә
Торган мәллә әби сәхәргә? –
Күзләремне ертып баса идем,
Җыенгандай ерак сәфәргә...

Мич алдында тезләремне кочып
Утырам мин, утка күз салып...
Мич төбендә алсуланып пешкән
Бөтен икмәк төсле кызарып.

2. Аның белән бергә сәхәр ашыйм,
Ул җибәрсә учак тергезеп,
Ялгана күк иде төн белән көн
Арасында булган бер өзек.

...Күзләремдә янган очкыннарны
Күреп соклансагыз берегез...
Шул мичләрдә дөрли-дөрли янган
Утлар очкыны дип белегез.

Мосафир

Р. Әхмәтҗанов А. Фәйзрахманов




9
Җил - ләр - гә би - рел - гән җил - кән - дәй а(е) - ры - лып
Ко - яш - ка та - бы - нып кит - сәң дә көнь - як - ка,
11
кит - тең син баш и - еп яз - мыш - ка.
ка - рар - сың и - ле - нә, бу як - ка!
8va
13
Күк - рә - гең то - тар - сың, са - гы - нып е - лар - сың – и - лең - не та - бар - сың
16
сул як - та, Ва - та - ның хәл - лә - рен җил - ләр - дән со - рар - сың,



2. Илеңнән киткәндә карадың бер якка –
Судагы ямь-яшел кыякка.
Кояшка табынып китсәң дә көньякка,
Карарсың илеңә, бу якка!
Күкрәгең тотарсың,
Сагынып еларсың –
Илеңне табарсың сул якта,
Ватаның хәлләрен җилләрдән сорарсың,
Кем булыр, кем булмас ул чакта.

Мөлдерәмә шатлык

Р. Әхмәтҗанов

А. Фәйзрахманов




16
тең – кил мә - сен, бу - лыр - бул-мас яр-лар ку - лын бир - мә-сен. Ки -
19
лер бер ут, са - быр ит - че, – ян - ды - рыр; Мә -
21
хәб - бәт-нең тат - лы я - шен там - ды- рыр... Ки -
23
лер - кил-мәс мә-хәб - бә - тең – кил - мә - сен, бу -


25
1.
лыр - бул-мас яр - лар ку-лын бир - мә - сен. Ки -
28
Тәмамлау өчен
//бир - мә - сен.
mf
32
35

1. Бәхет сине онытмасын, – яратсын;
Тик сөйгәнең чәчең үрсен, таратсын...
Килер-килмәс мәхәббәтең – килмәсен,
Булыр-булмас ярлар кулын бирмәсен.

Кушымта:

Килер бер ут, сабыр итче, – яндырыр;
Мәхәббәтнең татлы яшен тамдырыр...
Килер-килмәс мәхәббәтең – килмәсен,
Булыр-булмас ярлар кулын бирмәсен.

2. Сүнәр-сүнмәс ут пыскыса ераста,
Юкка өметең дөрләмәсен йөрәктә...
Тулыр-тулмас кайтса кайтыр чиләген,
Мөлдерәмә шатлык булсын йөрәгең!

Кушымта:

Килер бер ут, сабыр итче, – яндырыр;
Мәхәббәтнең татлы яшен тамдырыр...
Килер-килмәс мәхәббәтең – килмәсен,
Булыр-булмас ярлар кулын бирмәсен.



Оныт...

Д. Маликов (Зөлфәт) А. Фәйзрахманов



13

ва күр - мә - сен җа - ны - ңа яз - гы яң - гыр бу -

16

лып. Чәч - лә - ре - ңә ти - яр - ти - мәс у -

19

зар яз - гы бо - лыт, таң нур - ла - ры сыр -


22
па - ла - ныр чәч - лә - ре - нә ку - нып... Дәш -
25
ми - мен дә, ча - кыр - мыйм да – сөй - ләр ку - е бо -
28
лыт – я - ва кал - са йө - рә - ге - нә яз -


31
Coda
гы яң - гыр бу - лып... Дәш - //ва кал - са йө -
34
рә - ге - нә яз - гы яң - гыр бу - лып...
37
40



2. Күтәрелмәсен керфегең
Мөлдерәмә тулып...
Болытларга карый күрмә –
Оныт мине, оныт!

Кушымта:

Чәчләреңә тияр-тимәс
Узар язгы болыт,
Таң нурлары сырпаланыр
Чәчләреңә кунып...
Дәшмимен дә, чакырмыйм да –
Сөйләр куе болыт –
Ява калса йөрәгеңә
Язгы яңгыр булып...

Өмет

Инструменталь әсәр

А. Фәйзрахманов



* 1-2 тактларны башкармаска мөмкин. (1-2 такты можно пропустить)


14
17
3
20
24


27
4
1.
30
2.
33
5
1.
36
2.
38
𝄋
mf
mp

Синең өчен яшим

Р. Фәйзуллин А. Фәйзрахманов




14
ы - ша - нып. Я - ңа ту - ар таң - га ы - ша - нып.
17
Си-нең ө - чен я - шим, си-нең ө - чен я - нам, си-нең күз - ләр бе - лән
20
кү - рәм дөнь - я - ны. Са - гы-шым-ның, хис-лә - рем-нең юк чик - я - ры,
23
га-шыйк бул-ган ке - ше аң - лар ми-нем җан - ны. Са - гы-шым- ның, хис-лә -

26

рем - нең юк чик - я - ры, га - шыйк бул - ган ке - ше

28

Кабатлау өчен | Тәмамлау өчен

аң - лар ми - нем җан - ны. ны.

31

33

2. Белмим алда ниләр көтәсең,
Сагыш баскач, ни хәл итәсең?
Карап калыйм күзем тулганчы,
Вакыт җиткәч, тотмам, китәрсең.
Вакыт җиткәч, тотмам, китәрсең.

Кушымта:

Синең өчен яшим, синең өчен янам,
Синең күзләр белән күрәм дөньяны.
Сагышымның, хисләремнең юк чик-яры,
Гашыйк булган кеше аңлар минем җанны.


Сиңа гына

Ж. Сөләйман А. Фәйзрахманов




16
лы и - ре - нең - дә соң - гы миз - гел - лә - рем үт - сә -
19
че. Куп - шы чәч - лә - рең - не ү -
21
рер - сү - тәр и - дем, та - рар и-дем бу - лып җил - та -
24
рак, тын - мас и - дем һич тә, син - нән туй - мас и - дем, йә


27
ша - шы - нып и - сеп, йә – - сал - мак. Тын - мас и - дем һич тә, син -
31
нән туй - мас и - дем, йә ша - ша - нып и - сеп, йә – сал -
34
мак.
А..
p
mf
38



2. Якты йолдыз булсам, синең йөрәгеңә
Тамар идем түзми, җай табып...
Аккош булсаң, разый, күлдә шәүләң булыйм,
Каурыйларың тирбим чайкалып...

Кушымта:

Купшы чәчләреңне үрер-сүтәр идем,
Тарар идем булып җил-тарак,
Тынмас идем һич тә, синнән туймас идем,
Йә шашынып исеп, йә – салмак.
Тынмас идем һич тә, синнән туймас идем,
Йә шашынып исеп, йә – салмак.

3. Балан булсам әгәр, әче димәс идең,
Тел очыңа өзелеп төшсәм дә,
Кызыллыгым минем – янып яратудан,
Әчелегем – өзелеп көткәннән.

Кушымта:

Купшы чәчләреңне үрер-сүтәр идем,
Тарар идем булып җил-тарак,
Тынмас идем һич тә, синнән туймас идем,
Йә шашынып исеп, йә – салмак.
Тынмас идем һич тә, синнән туймас идем,
Йә шашынып исеп, йә – салмак.

Туган як вальсы

Г. Зәйнашева А. Фәйзрахманов




17
И, ту - ган як, җәй - ге таң - на - рың - да кай-
21
1.
тып гар-мун уй - нар - мын ир - кәм ян - на - рын - да.
9
25
2.
Тәмамлау өчен
//да.
//да.
кай - тып гар-мун уй - нар-мын ир-
9
29
rit.
кәм ян - на - рын - да.

1. Кайтырмын, кайтырмын туган ягыма.
Көтсен! Әйтегез яшьлек ярыма.
Кушымта:
И, туган як, җәйге таңнарыңда
Кайтып гармун уйнармын
Иркәм яннарында.

2. «Китте дә – кайтмый», – дип уйлый күрмәгез.
Чит ят илләрдә озак йөрмәбез.
Кушымта.

3. Туган як туфрагын китсәм дә ташлап,
Йөртәм йөрәктә җылысын саклап.
Кушымта.

4. Яшьлектә сөйгән яр – язгы гөл икән,
Саф мәхәббәтнең кадерен бел икән.
Кушымта.



Агыйм дисәм, барыйм дисәм,
Аккош бүлә юлымны.

Халык җыры

Тынма, давыл!

Х. Туфан

А. Фәйзрахманов




17
Өс - тә – дул - кын, ас - тан – уп - кын кул - лар са - ла са - лы - ма.
21
Сук - ма, дул - кын, уп - ма, уп - кын кай - тыйм я - рым я - ны - на.
25
Тәмамлау өчен
Уп - кын - на - рың бер - ни тү - гел, ба - тыр - ма тик моң - лык -



2. Давыл тынды, дулкын тонды,
Аккош бүлә юлымны:
Юксыңдыр син, сизәдер кош
Юлым бушка булуны...
Тынма, дәрья, айка, чайка:
Кунмәгәнмен тынлыкка.
Упкыннарың берни түгел,
Батырма тик моңлыкка...

Үтте ул көн...

Р. Әхмәтҗанов А. Фәйзрахманов




20
көн, оч - ты җил - гә тө - тен – оч - кан го -
24
мер... Тәң-гәл и - кән ба-ры - сы – бер - гә- бер... Оч-кан тө - тен, җил-гә оч-
28
кан го - мер – моң-лы тө-шем бе - ләң бер - мә бер!
mf
Тәмамлау өчен
32



2. Ни калдырдың?..
Ә, ул гүзәллекләр,
Ул киңлекләр –
Билдән ак чәчәк!
Ике кулда чайпалдырып савыт,
Ак сөлгесен иң өстенә салып,
Ни китерә
Көткән Киләчәк?

3. Үкен, үкен – инде үтте ул көн.
Ни китерә,
Йә, әйт, Киләчәк!
Дүрт күз белән аны көтеп алып, –
Әллә язмыш балы,
Әллә... агу –
Күпме икән аңа
Бирәчәк?

Ышаныч


Р. Фәйзуллин

А. Фәйзрахманов




10
ө - чен жан а(я) - мый я - шәү - че - ләр и - реш -
12
Кушымта:
сен - нәр те - лә - ге - нә! Җир йө - зен - дә күп - ме
14
а - на ба - ла ба - га, ө - мет - лә - неп ты - ныч
16
көн - гә, як - ты көн - гә! Һәм - мә ке - ше шат я -


18
шә - сен, бә - хет җы - рын
җыр - лый - җыр - лый ту - ган
20
җир - дә, ту - ган тел - дә!
Һәм - мә ке - ше шат я -
22
шә - сен, бә - хет җы - рын
җыр - лый - җыр - лый ту - ган
24
Кабатлау өчен
җир - дә, ту - ган тел - дә!



2. Гөл чәчәкле, алсу таңлы бу дөньяга
Туа кеше бәхет өчен, шатлык өчен.
Ил язмышы кыл өстендә торса әгәр,
Фидаиләр башын сала хаклык өчен.

Кушымта:

Җир йөзендә күпме ана бала бага,
Өметләнеп тыныч көнгә, якты көнгә!
Һәммә кеше шат яшәсен, бәхет җырын
Җырлый-җырлый туган җирдә, туган телдә!

Юкә чәчәге җыйганнар

Р. Фәйзуллин А. Фәйзрахманов




11
Ю - кә чә - чә-ге җый - ган - нар ак яу-лык - лы а - па - лар.
13
Ак төе-ен - чек-ләр - гә төй - нәп сау - лык а - лып кай - та - лар.
Тәмамлау өчен
15
17

1. Юкә чәчәге җыйганнар
Ак яулыклы апалар.
Ак төенчекләргә төйнәп,
Саулык алып кайталар.
Дөнья күргән апалар бу,
Тормыш кичкән апалар!
Җиләк-как койган апалар,
Сөлге чиккән апалар!

Кушымта:

Юкә чәчәге җыйганнар
Ак яулыклы апалар.
Ак төенчекләргә төйнәп
Саулык алып кайталар.

2. Кемнедер оныгы көтә,
Кемнедер улы көтә...
Юкә чәчәген тансыклап,
Чәй эчәр кышлар җитә.
Ниндидер бер пакълек балкый
Кыяфәт, йөзләрендә.
Затлы кеше әверелә ул
Яшәүнең бизәгенә.

Кушымта:

Юкә чәчәге җыйганнар
Ак яулыклы апалар.
Ак төенчекләргә төйнәп
Саулык алып кайталар.



Язмышның борылган төшендә

Р. Әхмәтҗанов А. Фәйзрахманов




13
да, ми - нем күк, бо - ры - лып ка - рый-
15
мы үтел-гән юл - ла - рын? Я-шим тик, туп-ту-ры, үч и-
18
теп, үзем һәм бү - тән - нәр ө - чен дә. Бо - рыл -
21
мыйм ә - ле мин, төз я - шим, яз - мыш -



2. Елганың борылган төшендә
Кычкырып әйләнә тәкәрлек...
Аккан су, искән җил – мәңгелек,
Гомерләр – бер генә сәфәрлек!..

Кушымта:
Яшим тик, туп-туры, үч итеп,
Үзем һәм бүтәннәр өчен дә.
Борылмыйм әле мин, төз яшим,
Язмышның борылган төшендә!..

Яратуга хәтле

Р. Мингалим А. Фәйзрахманов




9
"Соң - ла - ма - гыз!" – ди - еп, ки - ңәш би - рә а - лам. –
11
Тор - мыш ә - нә шу - лай һәм шул ки - леш ка - ла.
13
Я - ра - ту - га хәт - ле а - ра шун - дый е - рак,
15
Я - ра - тыр - сыз соң - рак, са - гы - ныр - сыз соң - рак.

1. Бик яратып бардым,
Бардым бераз соңлап.
Бик сагынып бардым,
Бардым бераз соңлап.
«Соңламагыз!» – диеп,
Киңәш бирә алам. –
Тормыш әнә шулай
Һәм шул килеш кала.

Кушымта:

Яратуга хәтле
Ара шундый ерак,
Яратырсыз соңрак,
Сагынырсыз соңрак.

2. Барсагыз да йөгереп,
Минем кебек итеп,
Барсагыз да очып,
Мине күпкә үтеп:
«Соңламагыз!» – диеп,
Киңәш бирә алам. –
Тормыш әнә шулай
Һәм шул килеш кала.

Кушымта:

Яратуга хәтле
Ара шундый ерак,
Яратырсыз соңрак,
Сагынырсыз соңрак.

Яшьлектәге җыр (Телеграм баганасы...)

Телеграм баганасы...
Чыбыклары салынган.
Бу дөньяда без генәме
Яшьлекләрен сагынган!

(Авыл көе)

Р. Фәйзуллин

А.Фәйзрахманов





2.Юлга чыккач, без аларны
Саный-саный атладык.
Туган якка каерылып
Карый-карый атладык.
Кушымта:
Телеграм баганасы
Берәү түгел, йөзәү ул!
Яшь чакларда җырланган җыр
Үзәкләрне өзә ул!

3.Төпләрендә ял иткәндә
Гүләүләрен тыңладык.
Моңсу чакта – телеграм
Көйләренә җырладык.
Кушымта.

4. ...Телеграм баганасы...
Ник берсе авыш тора?
Искән җилләр, үткән еллар
Аера, кавыштыра.
Кушымта.
5. Телеграм баганасы...
Ул безнең баганалар!
Яшьлек еллары хәтердә
Көннән-көн яңаралар.
Кушымта.
6. «Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул!
Сагынасыңмы, дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул!»
Кушымта.

ЭЧТӘЛЕК

1.	«Абзыеңның кәләпүше»	*И. Юзеев сүзләре*	8
2.	«Авылыма кайту»	*С. Әхмәтҗанова сүзләре*	11
3.	«Ак поэма»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	14
4.	«Алып калыр өмет»	*М. Әгъләмов сүзләре*	18
5.	«Әгәр миңа ышанмасаң»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	21
6.	«Әни ишетми калган җыр»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	24
7.	«Әни»	*К. Сибгатуллин сүзләре*	27
8.	«Әнкәем-сердәшемә»	*С. Әхмәтҗанова сүзләре*	29
9.	«Без, бәләкәй чакларда»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	31
10.	«Борчылма»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	34
11.	«Елмай әле бер генә»	*Р. Мингалим сүзләре*	37
12.	«Җәйләр соңы»	*И. Иксанова сүзләре*	40
13.	«Имин генә булсын татар-йорт!»	*Ж. Сөләйман сүзләре*	43
14.	«Истәлек»	*Инструменталь әсәр*	46
15.	«Кичер, болыным»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	49
16.	«Кичке кошлар»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	51
17.	«Кошларымны көтәм»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	54
18.	«Көзге җыр»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	57
19.	«Көзге мәхәббәтем»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	60
20.	«Кыз гомере»	*Г. Афзал сүзләре*	64
21.	«Мәхәббәт көянтәсе»	*Л. Шагыйрьҗан сүзләре*	67
22.	«Мизгел»	*М. Әгъләмов сүзләре*	70
23.	«Мосафир»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	75
24.	«Мөлдерәмә шатлык»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	78
25.	«Оныт»	*Зөлфәт сүзләре*	82
26.	«Өмет»	*Инструменталь әсәр*	87
27.	«Синең өчен яшим»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	90
28.	«Сиңа гына»	*Сөләйман сүзләре*	93
29.	«Туган як вальсы»	*Г. Зәйнашева сүзләре*	97
30.	«Тынма, давыл!»	*Х. Туфан сүзләре*	100
31.	«Үтте ул көн»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	103
32.	«Ышаныч»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	106
33.	«Юкә чәчәге җыйганнар»	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	110
34.	«Язмышның борылган төшендә»	*Р. Әхмәтҗанов сүзләре*	113
35.	«Яратуга хәтле»	*Р. Мингалим сүзләре*	116
36.	«Яшьлектәге җыр» («Телеграм баганасы»)	*Р. Фәйзуллин сүзләре*	119

Кереш мәкалә авторы, җыентыкны төзүче – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, профессор, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе

А. Ф. ФӘЙЗРАХМАНОВ

БОРЧЫЛМА

җырлар һәм романслар

Редакторы һәм төзүчесе Татарстанның атказанган артисткасы Г. Ф. Шәрапова

Ноталарны язды И. И. Фәйзетдинов

Музыкаль редакторы һәм компьютерда биткә салучы И. Ф. Камалов

© А. Ф. Фәйзрахманов, 2018 ел.

Тиражы 500 данә.

«Халкыбыз мирасы» нәшриятында басылды.
420073, Казан шәһәре, Спортивная, 33.